**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 08 » 10 2021 № 310

Аксубаево

Яшь гаиләләргә торак сатып алу яки индивидуаль торак йорт төзү өчен бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Аксубай муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының 2021 елның IV кварталына уртача базар бәясе нормативын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.10.2019 ел, №888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы һәм сыйфатлы торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 12.02.2020 ел, №81 карары белән расланган «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру максатларында, «Социаль программаларны тормышка ашыру максатларында торак базарын тикшерү турында» 17.09.2021 ел, №206 «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр союзы» КП тарафыннан үткәрелгән Аксубай муниципаль районының Аксубай ш. т. п. һәм Аксубай муниципаль районында торак биналарның бер квадрат метр бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренү нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасы өчен яшь гаиләләргә торак сатып алу яки индивидуаль торак йорт төзү өчен бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар бәясе нормативын 29 000 сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) халыкка хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.И. Исламовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев